КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 28 октябрь г.Казань № 933

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Хөкүмәтендә проект эшчәнлеген оештыру турында» 2019 ел, 20 июнь, 504 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Хөкүмәтендә проект эшчәнлеген оештыру турында» 2019 ел, 20 июнь, 504 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 16 февраль, 83 нче; 2023 ел, 5 апрель, 414 нче; 2023 ел, 28 июль, 904 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

преамбулада «2030 елга кадәр чорга Россия Федерациясе үсешенең илкүләм максатлары турында» 2020 елның 21 июлендәге 474 номерлы» сүзләрен «2030 елга кадәр чорга һәм 2036 елга кадәр перспективага Россия Федерациясе үсешенең илкүләм максатлары турында» 2024 елның 7 маендагы 309 номерлы» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы Хөкүмәтендә проект эшчәнлеген оештыру турындагы нигезләмәнең 2 пунктындагы икенче абзацында «2030 елга кадәр чорга Россия Федерациясе үсешенең илкүләм максатлары турында» 2020 елның 21 июлендәге 474 номерлы» сүзләрен «2030 елга кадәр чорга һәм 2036 елга кадәр перспективага Россия Федерациясе үсешенең илкүләм максатлары турында» 2024 елның 7 маендагы 309 номерлы» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы<br>Премьер-министры А.В.Песошин